**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.п. № 15 «30» март 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселогы Советының 02.07.2018 №28 карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында (15.10.2018 №49, 28.02.2019 №10, 20.08.2019 №37, 16.12.2020 №18 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 21.12.2021 № 414-ФЗ Федераль Законына, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 26.01.2023 № 1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына ярашлы,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы шәһәр тибындагы Актүбә поселогы Советы 02.07.2018 № 28 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы поселок» муниципаль берәмлегендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Нигезләмәгә (15.10.2018 №49, 28.02.2019 №10, 20.08.2019 №37, 16.12.2020 №18 карарлар редакциясендә) үзгәреш кертергә 1.7 пунктның икенче абзацындагы «Татарстан Республикасы Президентына» сүзен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталындагы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Актүбә шәһәр тибындагы поселок Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А.Л. Севостьянов